Мәмәшир авыл җирлеге Советы

Карар

2022 елның 25 нче ноябре № 33

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 24 нче ноябрендәге 39 номерлы
Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 39 номерлы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 27 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 16 номерлы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 нче һәм 4 нче пунктларны өстәргә:

«3) Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

4) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.»

2. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 34 номерлы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарының 3.1 пунктындагы 3 һәм 4 нче пунктчалары нигезләмәләренең (әлеге карар редакциясендә) гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Мәмәширавыл җирлеге башкарма комитетына «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендэге39 номерлы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарының 3.1 пунктның 3 һәм 4 нче пунктчаларында (әлеге карар редакциясендә) күрсәтелгән гражданнар исемлеген формалаштырырга һәм салым органына тапшырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов